**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь | № 666

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында»;

преамбулада «оешмаларга» сүзен «учреждениеләргә» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «хезмәтләр» сүзе алдыннан «дәүләт учреждениеләре күрсәткән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Баш ветеринария идарәсенә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» белән берлектә, үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартларын эшләүне;

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары үтәлешен исәпкә алып, дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә дәүләт йөкләмәсен формалаштыруны.»;

3 пунктның икенче һәм өченче абзацларында «хезмәтләр» сүзе алдыннан «муниципаль учреждениеләр күрсәткән» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында нигезләмә»;

1.1 пунктта:

«Татарстан Республикасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәткән һәм башкарган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләренә кертелгән (алга таба – дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты) һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү тармагында дәүләт хезмәтләренә таралмый»;

пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Халыкка социаль хезмәт күрсәтү тармагында дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре» 2013 елның 28 декабрендәге 442- ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртипләре составында билгеләнә.»;

1.2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче һәм дүртенче абзацларда «оешмалар» сүзләрен «учреждениеләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта:

икенче абзацта «бүтән юридик затлар», «яки мәҗбүри медицина иминияте чаралары» сүзләрен төшереп калдырырга, «алучылар» сүзеннән соң «дәүләт» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләре дигәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең төп (тармак) исемлекләре нигезендә учреждениеләрнең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарган башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга дәүләт йөкләмәләрен төзү максатларында билгеләнгән тәртиптә формалашкан һәм расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара тораган дәүләт хезмәтләре һәм эшләре исемлекләре аңлашыла.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә формалашалар һәм расланалар.»;

1.5 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтен алучының дәүләт хезмәтен күрсәтүче учреждение, аның вазыйфаи заты белән нәтиҗәле багланышларын булдыру;»;

җиденче абзацта «алучылар» сүзеннән соң «дәүләт» сүзен өстәргә;

сигезенче абзацта «алучылар» сүзеннән соң – «дәүләт» сүзен, «каралган» сүзе алдыннан өстәргә «законнарда» сүзен өстәргә;

2.9 пунктта «күрсәтүче оешма» сүзләрен – «күрсәтүче учреждение» сүзләренә, «оешма» сүзен «учреждение» сүзенә алмаштырырга;

2.10 пунктның икенче абзацында «күрсәтүче оешма» сүзләрен «күрсәтүче учреждение» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

2.14 пунктның беренче абзацында «аны күрсәтүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләреннән соң «аларның чик мәгънәләрен һәм авырлык коэффициентларын күрсәтеп» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандарты проектын эшләү Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләп чыгару һәм норматив хокукый җайга салу вазыйфаларын башкаручы башкарма органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары дәүләт, муниципаль хезмәтләр һәм эшләрнең төп (тармак) исемлегендә хезмәтнең бердәй коды булган ведомство хезмәтләренең һәрбер җыелмасына билгеләнә.»;

4.1 пунктта «оешмалар» сүзен «учреждениеләр» сүзенә алмаштырырга;

4.5 пунктта өченче абзацта «оешмалар» сүзен «учреждениеләр» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1095 нче; 2012 ел, 19 июнь, 525 нче, 2012 ел, 20 декабрь, 1107 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында»;

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре» сүзләрен «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына» сүзләре алдыннан «дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен – «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Икътисад

министрлыгына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Баш ветеринария идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына» сүзләре алдыннан «дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен, 1 февральгә кадәр, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне планлаштыру һәм мониторинглауның мәгълүмат ресурсын формалаштыру бердәм ведомствоара системасы составында дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлүе турында хисапларны формалаштыру һәм раслау.»;

3 пунктта:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү буенча башкарылган эш турында бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән, гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары гамәлгә ашырган дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәләре үтәлүе турында хисапларны системалаштыруны һәм эшкәртүне;»;

өченче абзацта «дәүләт хезмәтләре» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «15 февраль» сүзләрен «1 апрель» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт хезмәтләре» сүзләре алдыннан «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә һәм башкара торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең ведомство исемлекләренә кертелгән гамәлдә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең (алга таба – дәүләт хезмәтләре) сыйфатын тикшерүдә тотуны камилләштерү һәм кулланучыларның күрсәтелә торган дәүләт

хезмәтләре сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен билгеләү максатларында эшләнде.»;

1.2 пунктның дүртенче абзацында «күрсәтүче юридик затлар» сүзләрен «күрсәтүче» сүзенә алмаштырырга, «(алга таба – оешмалар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4 пунктта «оешмалар күрсәткән» сүзләрен «дәүләт учреждениеләре күрсәткән» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2.1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.3. Дәүләт хезмәте сыйфатын билгеләүче критерийларның планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт учреждениесенең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне планлаштыру һәм мониторинглауның мәгълүмат ресурсын формалаштыру бердәм ведомствоара системасы составында дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт йөкләмәсе үтәлүе турында хисаплары составында формалаша һәм раслана.»;

2.2.1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2.3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.4. Тикшерү чараларын үткәрү турында актлар күчермәләрен теркәп, тикшерү чараларын үткәрү нәтиҗәләре:

тикшерү чаралары тәмамланган көннән соң календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының рәсми сайтында урнаштырыла;

хисап елы нәтиҗәләре буенча, хисап елыннан соң килгән елның 1 февраленнән соңга калмыйча, аларны гомумиләштерү һәм шуннан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә җибәрелә.»;

3.1 һәм 3.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү агрегацияләнгән индикаторларны файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.2. Дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләүнең агрегацияләнгән индикаторы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$AI_i = \sum_{i=1}^{n} I_i \times K_i,$$

монда:

$AI_i$ –дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләүнең i-критериясе буенча дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләүнең агрегацияләнгән индикаторы;

$I_i$ – дәүләт хезмәте сыйфатының нормалаштырылган i-критериясе;

$K_i$ – дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләүнең i-критериясенең чагыштырма авырлык коэффициенты;

n – дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү критерияләре саны.»;

3.5, 3.7, 3.8 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү нигезендә түбәндәгеләр формалаша:

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче учреждениеләр рейтингы (алга таба – учреждениеләр рейтингы);

дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт учреждениеләренең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары (алга таба –ДХБО).

Учреждениеләр рейтингы күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре күзлегеннән чыгып формалаша.

Дәүләт хезмәтләре сыйфатын интеграль бәяләү нигезендә, бәяләнүче ведомстводагы учреждениеләр санын исәпкә алып,  хисап елына ДХБО рейтингы формалаша.»;

3.9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләүнең мәгънәсен ачып бирү түбәндәгечә башкарыла:»;

таблицада  «Җыелма бәялү» сүзләрен «Агрегацияләнгән индикатор мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә билгеләнгән эшчәнлек тармагында өч ай эчендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартларына үзгәрешләр кертү буенча тиешле норматив хокукый актлар проектларын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

Татарстан Республикасы  
Премьер-министры  
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин